ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

______________ с. Верхний Услон ______________

Югары Ослан муниципаль районының җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының бүленгән полосаларын һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм алардан файдалану тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

"Россия Федерациясе Җир кодексына, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм "Россия Федерациясе Җир кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" Федераль законның 5 статьясындагы 2 өлешенең үз көчен югалтуын тану хакында" 2024 елның 26 декабрендәге 485-ФЗ номерлы Федераль закон, Югары Ослан муниципаль районы Уставы нигезендә, Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 08 декабрендәге 1614 номерлы карары белән расланган Югары Ослан муниципаль районы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының бүленгән полосаларын һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм куллану тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Тәртипнең 1.3.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1.3.3. Автомобиль юлының юл буе полосалары - автомобиль юлының беренче, икенче яисә өченче категориядәге бүленгән полосасына якын урнашкан һәм чикләрендә юл хәрәкәте иминлеге таләпләрен тәэмин итү максатларында җир кишәрлекләреннән (җир кишәрлекләре өлешләреннән) файдалануның махсус режимы, шулай ук автомобиль юлын үстерүнең перспективаларын исәпкә алып, автомобиль юлын реконструкцияләүнең, капиталь ремонтлауның, ремонтлауның, аның саклanышының нормаль шартлары билгеләнә торган территорияләр;

2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе
вазыйфаларын вакытлыча башкаручы А.А. Ахметшин